ТҮЛӘП УКЫТУ
«Бишле» билгесе өчен балага акча бирү уку теләген уятырмы?
> 2



СОҢГЫ ЧИК
«Мин мәгънәне үлемдә генә күрәм!» – дияргә яшьләрне нәрсә этәрә?
> 3

ҖИҢҮДӘН БАШЛАНДЫ
«Ак барс»ка Гагарин Кубогын отар өчен тагын өч җиңү кирәк
> 4

СӨТЛЕБИКӘЛӘР БИКӘСЕ
38 ел буе сыер сауган Рушания Ибраһимова малкайларына исем белән генә дәшә
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 56 (29023) | Чәршәмбе | 19 апрель | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ТАВЫШЛАРНЫ ЯЗЫН САНЫЙЛАР

Язның иртә килүе төзүчеләрне дә ашыктыра. Быел республикада иҗтимагый киңлекләр һәм ишегалларын бер айга диярлек иртәрәк төзекләндерә башлаганнар. Ел ахырына кадәр Татарстанда 1 меңгә якын ишегалдын тәртипкә китерәчәкләр. Ә республиканың 13 районында яшьләр өчен экстрим-парклар ачылачак. Интернетта исә киләсе елда башкарылачак эшләр өчен тавыш бирүнең иң кызган чагы. Ә сез әле тавыш бирдегезме?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Республикада иҗтимагый киңлекләрне һәм ишегалларын төзекләндерүгә бәйле программаларга зур урын бирелә. Быел 960 ишегалды территориясе, 68 парк, сквер һәм яр буе тәртипкә китереләчәк. Төзүчеләр эшкә керешкән дә инде.

– Ишегалларында эш башланды. Иң элек асфальт юлларны яңарталар. Быел ишегалларын тәртипкә китерү өчен генә дә 9 миллиард сум акча тотылачак. Агымдагы елда республиканың 13 районында яшьләр өчен экстрим-киңлекләр дә барлыкка киләчәк, – диде «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында «Шәһәрләрне үстерү институты» фонды директоры Наилә Зиннәтуллина. – Татарстанның 29 районында яшьләр өчен махсус ял мәйданнары бар инде. Бу юнәлештәге эш алга таба дәвам иттереләчәк. Республиканың һәр районында да экстремаль спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен киңлекләр төзергә телибез.

Билгеле булганча, 2020 елдан бирле төзекләндереләчәк иҗтимагый киңлекләрне сайлап алуда халык та катнаша. Моның өчен Татарстан Дәүләт хезмәтләре порталы һәм кесә телефонындагы «Услуги РТ» кушымтасы аша онлайн тавыш бирү дә җитә. Казанда яшәүчеләр, мәсәлән, Әгерҗе паркы өчен дә тавыш бирә ала. Былтыр бу эштә 207 меңнән артык кеше катнашкан. Онлайн тавыш бирү илкүләм дәрәҗәдә оештырыла. Ә аның кысасында җиңү яулаган җирлекләр «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» илкүләм проектына кертелә. Татарстанда яшәүчеләр иҗтимагый киңлекләр белән беррәттән, төзекләндереләчәк ишегаллары өчен дә тавыш бирә ала. Сүз уңаеннан, «Безнең ишегалды» программасы Татарстанда Рәис Рөстәм Миңнеханов тәкъдиме белән 2019 елдан бирле тормышка ашырыла. Ул 2014 елга кадәр төзелгән күпфатирлы йортларның ишегалларын колачлый. Аның кысасында, җәяүлеләр һәм машина юллары төзекләндерелә, балалар һәм спорт мәйданчыклары корыла, эскәмияләр, яктырткычлар һәм чүп савытлары урнаштырыла, көнкүреш калдыкларын ташлау өчен аерым урыннар булдырыла. Республиканың 11 районында программа тәгәлләнгән дә инде. Биредә ишегалларын ямьләндереп бетергәннәр. Ел азагына кадәр Татарстандагы тагын ике районда эш бетәчәк дип фаразлана.

Интернетта исә киләсе елда башкарылачак эшләр өчен тавыш бирү башланды. Ул 31 майга кадәр дәвам итәчәк.

– Киләсе елга тәкъдим ителгән исемлектә республика күләмендәге 2145 ишегалды һәм 267 иҗтимагый киңлек бар, – диде Татарстан төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры урынбасары Алексей Фролов. – Иң мөһиме – республикада яшәүчеләр тавыш бирүгә битараф калмасын иде.

Бу хакта «эшлекле дүшәмбе»дә Казан башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Игорь Куляжев та искә төшерде. Баксаң, былтыр башкалада төзекләндереләчәк иҗтимагый киңлекләр өчен шәһәрдә яшәүчеләрнең нибары 6 проценты гына тавыш биргән икән.

– Федераль программага эләгү өчен халык та төзекләндерүдә катнашырга тиеш. 14 яше тулганнар тавыш бирү хокукына ия булуын исәпкә алсак, Казанда яшәүче 1,1 миллион чамасы кеше дигән сүз бу. Быел сораштыруда катнашучылар узган елгы дәрәҗәдә генә булса, башкала, гомумән дә, исемлектән төшеп калырга мөмкин, – дип сөйләде ул.

Моңа җавап итеп, Илсур Метшин Казан халкына аңлырак булырга киңәш итте. Дәүләт хезмәтләре порталында «шәхси кабинет»ы булганнарга, тавыш бирүдә катнашырга өндәп, «сәлам хатлары» юллаганнар инде.

– Республикада яшәүчеләр күбрәк кесә телефонындагы «Услуги РТ» кушымтасын үз итә. Аларга 630 меңгә якын хат җибәрдек. Бүген-иртәгә «сәлам хатлары»н электрон адреслар буенча да юллаячакбыз, – диде Татарстан дәүләт идарәсенең цифрлы үсеш, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрының беренче урынбасары Илья Начивин.

Шуңа күрә кесә телефонына хат «ява» башласа, аптырап калмагыз.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Сан

Быел республикада төзекләндерү, коммуналь челтәрләрне яңарту, капиталь ремонт һәм төзелешкә бәйле барлыгы 44 республика программасы гамәлдә. Алар кысасында 51,7 миллиард сумлык эш башкарылачак дип фаразлана. Боларга өстәп, 6 илкүләм проект һәм 4 дәүләт программасы да эшли. Аларның гомуми бәясе 15 миллиард сумга якын тәшкил итә.

Иң мөһиме – онытмау

Быел Россиядә «Үлемсез полк» акциясе төрле төбәкләрдә төрлечә – җанлы һәм онлайн форматта узачак. «Россиянең үлемсез полкы» оешмасы рәистәше Геннадий Иванов әйтүенчә, кайбер шәһәрләрдә, иминлекне кайгыртып, чараны башкача оештырырга ният кылганнар. Әйтик, 9 Майда Калуга, Воронеж урамнары буйлап йөрүләр булмаячак. Террорчылыкка каршы чаралар көчәйтелгән Курск, Орел, Брянск һәм Белгород шәһәрләрендә исә акцияне үткәрү турында карар кабул ителмәгән әле. Россия Мәдәният министрлыгы, «Россиянең үлемсез полкы» хәрәкәтен оештыручылар бу төбәкләрдә бәйрәм чарасын ишегалларында, һәйкәлләр янында оештырырга тәкъдим иткән. Илнең башка төбәкләрендә «Үлемсез полк»ны, гадәттәгечә, урамнарда уздырырга ниятлиләр.

Геннадий Иванов билгеләп үткәнчә, автомобильчеләр машина тәрәзәләрен ветеран бабаларыбызның рәсемнәре белән бизәп тә искә алу чарасында катнашырга мөмкин.

Төп бурычлар билгеле

Татарстан Хөкүмәте, җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алып, быелга 5 өстенлекле бурычны билгеләгән. Республика Премьер-министры Алексей Песошин имзалаган карарда шул хакта сүз бара.

Документ нигезендә, бәяләр, тарифлар үсүне чикләү, товарлар һәм хезмәтләр сыйфатын яхшырту төп өстенлекле бурычлар булып торачак. Сораштыруда катнашучыларның 60 проценты диярлек азык-төлек һәм коммуналь хезмәтләр чыгымнарының зур булуын, «коммуналка» түләүләренең үзен-үзе акламавын күрсәткән.

Өстенлекле бурычлар исемлегенә шулай ук халыкның керемнәрен арттыру, социаль яклау эшен көчәйтү, социаль өлкәдә хезмәт күрсәтү сыйфатын һәм аннан файдалану мөмкинлеген булдыру, халыкның әхлагын, культурасын үстерү, коммуналь хезмәтләр сыйфатын яхшырту кергән.

Татарстанда үткәрелгән социологик тикшеренүләр нәтиҗәсендә тормыш сыйфаты начараю, хезмәт хакы аз булу, медицина хезмәтен күрсәтүдәге проблемалар, идарәче компанияләрнең эш сыйфаты «аксавы», торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләренә нәтиҗәле контрольнең булмавы, шулай ук рухи-әхлакый тәрбия роленең кимүе ачыкланган. Бу проблемаларны хәл итү республика хакимиятенең төп эш юнәлешләренә әйләнәчәк. Башкарылган эшләр турында быел 1 декабрьгә кадәр хисап тотачаклар.

Гомер буе утырачаклар

Россия Дәүләт Думасы дәүләткә хыянәт итүчеләргә җәзаны кырысландыруны күздә тоткан законга төзәтмәләр кабул иткән. Документ нигезендә, мондый җинаять өчен гомерлек төрмә җәзасы бирелергә мөмкин.

«РИА Новости» хәбәренә караганда, шпионлык итү, дәүләт сере булып торучы мәгълүматларны чит ил кешеләренә тапшыру, дошман ягына күчү яки чит дәүләткә Россиягә каршы эшчәнлегендә финанс ярдәме, башка төрле ярдәм күрсәтү дәүләткә хыянәт итү буларак бәяләнәчәк. Моңарчы гаеплеләргә, 500 мең сумга кадәр штраф белән, 20 елга ирektән мәхрүм итү янарга мөмкин иде.

Исегезгә төшерәбез: дәүләткә хыянәт иткән өчен җәзаны кырысландыру турында закон проектына төзәтмәләр Дәүләт Думасына 7 апрельдә кертелгән иде.

Борчыган мәсьәлә

Баланы саклыйсы

Янәшәбездә яшәүче күпләр кызамыкка каршы торырга әзер түгел. «Гемотест» лабораториясе белгечләре шулай дип чаң суга. 17 мең кеше арасында тикшеренү уздырганнан соң аларның 72 процентында кызамыкка каршы торырлык иммунитет юклыгын ачыклаганнар. Әлеге төркемгә бу чир белән бер тапкыр да авырмаган яки кызамыкка каршы прививка ясатмаган кешеләр керә, ди белгечләр.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов бу тикшеренү нәтиҗәләренә шикләнеп карый. Ник дигәндә, ул әлеге чиргә каршы антитәнчекләр барлыгын ачыклау өчен анализ тапшырган кешеләр арасында гына уздырылган.

– Әмма шунысы бәхәссез: кызамык – яшен тизлегендә таралучы бик мәкерле һәм куркыныч чир. Хәтта коронавирус та шулкадәр тиз йокмый. Кызамык йоктырган кеше белән аралашкан булсаң, 100 процент очракта үзең дә авырыячаксың. Әлеге чирдән ниндидер махсус дарулар, битлек ярдәмендә дә саклана алмыйсың. Хәтта өйдән чыкмыйча качып утыруның да файдасы булмаячак. Ник дигәндә, кызамык хәтта вентиляция юлы буенча да бик тиз таралырга сәләтле. Күпфатирлы торак йортта бер кеше кызамык йоктырган булса, ул йортта яшәгән бар кешегә дә шул чирне йоктыру куркынычы яный дигән сүз. Шуңа күрә әлеге чирдән фәкать вакцина ярдәмендә генә сакланып була, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Лопушев сүзләренә караганда, хәзерге вакытта Татарстанда кызамык йоктыруның 30 очрагы теркәлгән. Тагын 30 кешенең анализ нәтиҗәләре әлегә әзер түгел. Соңгы тапкыр әлеге чир Универсиада авылында яшәүче студент кызда ачыкланган иде.

– Илкүләм прививкалар календаре буенча, 55 яшькә кадәр кешегә кызамыкка каршы ике прививка ясалган булырга тиеш. Ул аңа гомере буена җитә. Бу прививкалар документ нигезендә теркәлгән булырга тиеш. Юкса еш кына: «Миңа балачакта кызамыкка каршы прививка ясалган булган инде, әни шулай дип әйтте», – ише сүзләрне еш ишетергә туры килә. Бу – ялгыш фикер. Әгәр кеше үзенә кызамыкка каршы прививка ясалганмы-юкмы икәнлекне төгәл белмәсә, ул моңа тәгаен инанып өчен эхинококка IgG антитәнчекләр анализы тапшырырга тиеш. Әгәр кешенең бу чиргә каршы иммунитеты юк икәнлеге ачыкланса, аңа кызамыкка каршы ике прививка ясатасы булачак. Ике прививка арасында өч ай вакыт үтәргә тиеш, – ди баш эпидемиолог.

Ахыры 3 нче биттә >

Сүзгә-сүз

«Татар-информ»

Талия МИҢНУЛЛИНА, Татарстанның инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе:

Иң мөһиме – икътисад өчен файда булсын. Татарстан һәм Россия предприятиеләренең җитди партнерлар табуларын, экспортка чыгуларын, инвестицияләр җәлеп итүләрен телим. Нәтиҗә буларак, бөтен эшебез безнең халык, аның тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән. Супермаркетлар эчендә күбрәк продукция, күбрәк брендлар барлыкка килсен, ил эчендә югары хезмәт хаклы эшкә күчү мөмкинлеге булсын.

(«KazanForum-2023» турында, «РБК Татарстан»га биргән әңгәмәсеннән)

ТАТАРСТАНДА – ЧИСТАРТУ ИКЕАЙЛЫГЫ

1 апрельдә республикада санитария-экология икеайлыгы башланды. Экологлар ике атна эчендә башкарылган эшләре турында хисап тотты.

Табигатькә зыян салуның ачыкланган очрагы	1371
Тәртипкә китерелгәне	730
Төзелгән беркетмә	298
Салынган штраф	130,5 мең сум
Юкка чыгарылган чүплек	345
Түгелгән каты көнкүреш калдыгы	38,5 мең куб. м
Өмәдә катнашучылар	87,6 мең кеше
Утыртылган агач һәм куак	10447

Сөенечле хәбәр!

2023 елның 10–20 апрель көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 жомга саны — **Ташламалы бәя 444 сум 54 тиен**, гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя 1051 сум 80 тиен**, гадәти бәясе – ~~1227 сум 30 тиен~~

Реклама 16+



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ӨСТЕНЛЕК КЫЙММӘТЛӘНҮГӘ КИТЕРӘ

Дөньякүләм ягулык бәяләренең төшүе Россия өчен ни аңлатуын һәркем белә. Без болай да рецессия шартларында яшибез. Түбәнәюнең процентлары зур булмавын уңышка саныйбыз. ОПЕК+ карарыннан соң нефть бәяләренең күтәрелүе шатландырган иде. Әмма башка «кара алтын» хуҗалары үз товарларын кыйммәткә сатканда, без алай ук кинәнә алмыйбыз шул. Санкцияләрнең ролен никадәр киметеп күрсәтергә тырышсак та, алар эшли һәм Россия икътисадына зыян сала. Әйе, Россия нефть дә кыйммәтләнде соңгы атналарда, әмма саннар алай ук куанычлы түгел. Федераль Финанс министрлыгы мәгълүматлары 15 марттан 14 апрельгә кадәр аралыкта Urals маркасының бәясе 51,15 долларга җиткән күрсәтә. Аннан алда Россия нефте уртача 50,8 долларга сатылган. Күрәбез, «түшәм» бәягә дә менеп җитеп булмый әле. Безне, Япония Россия нефтен кыйммәткә ала, дип сөендергәннәр иде, әмма японга сатылган нефтьнең күләме шулкадәр: черки томшыгы кадәр генә. Бензинны кыйммәткәрәк сату җаен тапканнар Мәскәүдә шулай да. Нафтага кушып, шуның исеме белән саталар икән. Болай эшләгәндә, бәясе «түшәм» бәядән кыйммәткәрәк чыга. Бу инде сер булудан туктады, димәк, озакламый ул юлны бикләрләр.

Углеводород табышы кимегәндә, ил икътисадын нигә алга этеп була? Башка тармакларны үстереп. Икътисадны алга өстери торган төп тармак – төзелеш. Бар дөньяда бу шулай. Шуңа күрә торак төзелешен үстерүгә өчен җитәкчеләр барын да эшләргә тырыша. Өстенлекле кредит бирү юлы аша башкарыла ул. Төзелеш арту бик күп заводларны эшле итә. Бу – шиксез. Әмма күпме генә этәргә тырышсалар да, тармак торгынлык һәм түбәнәю этабына керәп бара. Беренче кварталда цемент җитештерү 8 процентка кадәр кимегән. Бу өч-дүрт цемент заводының туктавына тиң икән. Дөрес, альтернатив технологияләр кулланү да цементка ихтыяҗны киметкән. Ләкин башка төзелеш материалларына да бәяләр төшүен искә алганда, кулланү кимүен чамалый алабыз. Торак йортларны сату кыенлаша. Кайбер шәһәрләрдә ихтыяҗ ике урынлы саннар белән кими. Кимемәс иде, бәяләр тешли генә түгел, чәчләрне үрә торгыза. «Российская газета»ның телеграм-каналы күптән түгел генә Мәскәүдә 7,6 кв. метрлы студия сатылуын хәбәр итте. Ят оясы кадәр шул торакның бәясе – 4,15 миллион сум. Ирек Фәйзуллин – Россиянең төзелеш министры – бернигә көн элек кенә төзүчеләргә: «...сатылсын өчен, бәяләрне бераз гына төшермисезме дип әйтәсе килә», – дип мөрәҗәгать итте.

Бәя күтәрелүнең төп этәргече – өстенлекле ипотека, әлбәттә. Базарда кыйкны шул кабарта. Өстенлекле ипотека өч ел дәвамында Россиядә торак бәясен 82 процентка күтәрде, диләр белгечләр. Кредитны айлык түләүләр күләме 2 тапкыр арткан. Сатып алынган торакның уртача мәйданы кимегән. Шундый өстенлек иде: кечерәк фатирны кыйммәткәрәк алаcың, күбрәк түлисең. Үзәк банк каршы бу өстенлеккә, әмма хөкүмәт якылый.

Россиядә

ДИЗЕЛЬ – РЕЦЕССИЯ ХӘБӘРЧЕСЕМЕ?

Дөньяда бара торган глобаль үзгәрешләр – дәүләтләрнең үзара монархы кузәтелмәгән дәрәҗәдә каршылыкка керүләре – процент капиталына корылган икътисадның җимерелү нәтиҗәсе ул. Без бөтен планета белән бергә очып кереп баручы зур кризис алдагы финанс тынтәрелешләренән шуның белән аерыла да. 2008 елгы кризисның хәтерлик әле. Ул чакта илләр үзара берләшергә, хезмәттәшлекне арттырырга тырышты. Уртак кагыйдәләр эшләделәр. Кораллы конфликтлар турында сүз дә булмады. Дөрес, ул вакытта эшләнгән кагыйдәләр зур сызланулы наркотик белән басу кебек кенә булды. Бүген шул кагыйдәләрнең җимеше өлгерә: банклар түнтәрелеш алдында, зур державалар, базарларны югалтып, җитештерүне киметәләр: рецессия дигән зәхмәт башлана. Бүгенге финанс системасы рецессияне туктатырлык дәва таба алмый инде, чөнки рецептлар искерде. Аларны файдалану чирнең көчәюенә генә китерә. Сәясәт лидерлар русның «против лома нет приема» дигән кагыйдәсен эшкә җигәргә әзерләнәләр. Масштаблы кораллы конфликтлар мәйданга чыгарга җыена.

Безне, АКШта моннан берничә атна элек булып үткән финанс түнтәрелеше туктады, хәл уңайланды, дип ышандырырга тырышалар. АКШның элекке финанс министры Хэнк Полсон: «Банк кризисы тәгалләнмәде, глобаль рецессия бик мөмкин», – дип белдерә. Аның сүзләрен аналитиклар раслый, чөнки җитештерүнең түбәнәюе мөмкин генә түгел, аның билгеләре АКШ, Кытай һәм Европа илләре икътисадларында күзәтелә дә инде. Соңгы көннәрдә бу зур икътисадларның өчесендә дә дизель ягулыгын куллану кими. Ягулыкка ихтыяҗ АКШта аның бәяләренең кискен төшүенә карамастан түбәнәя. Белгечләр моны сәнагать һәм кулланучылар активлыгы кимү билгесе дип саныйлар. Бу дүшәмбедә Brent маркалы нефтьнең бәясе төшү күзәтелде. Арзаную төп уенчыларның – ОПЕК+ илләренең «кара алтын» чыгаруны киметүләрен игълан итү фонында бара.

Ни өчен дизель ягулыгына ихтыяҗ кимүне куркыныч билге дип санныйлар? Йөк ташу нигездә шуны кулланып башкарыла. АКШта бу максатларда дизель ягулыгының 70 проценты, Кытайда 60 проценты тотыла. American Trucking Associations (Америка йөк ташучылар ассоциациясе) дизель ягулыгын куллану заводларда җитештерү түбәнәю, йөртләр төзелеше акрынаю, ваклап сату сәүдәсе кризисы нәтиҗәсендә кимүен әйтә.

Кытайдан да шундый ук хәбәрләр алына. Кытай Транспорт министрлыгы мәгълүматларыннан күренгәнчә, апрельнең беренче атнасында ил автомагистральләрендә йөрүче йөк автомобильләре саны 8 процентка кимегән. Дингез портларында контейнерлар ташу да 5 процентлык югалтуда. Европадан да шуңа охшаш хәбәрләр алына.

Опек+ илләренең күптән түгел генә ашыгыч рәвештә ял көннәрендә, утырышка да җыелып тормыйча, нефть чыгаруны кимету турында карарлар кабул итүләрен искә төшерик. Шул карар булмаса, баррель 70 доллардан күпкә түбәнрәк китәсе иде, диләр белгечләр.

ЧИККӘ ҖИТКӘЧ

Мөнәсәбәт

Моның җавабы да булачак. Молдовага эш сәфәре белән килгән Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановны илгә кертмәүләре турында белгечләр әнә шулай ди. Сүз бит ике ил арасындагы мөнәсәбәтләр генә түгел, ике төрки халыкның мәдәни һәм рухи элемтәләре турында да бара.

Рөстәм Миңнеханов бу елда «Халыклар дуслыгы – 2023» I Халыкара халыклар дипломатиясе конгрессында катнашырга тиеш иде.

– Әле күптән түгел генә Татарстанда булып киткән Виктор Петров (Гагаузия халык җыены депутаты, төбәк башлыгы вазыйфасына кандидат) һәм Александр Суходольский (Молдова парламентында Гагаузиядән депутат) белән бергә киңкырлы уртак эшчәнлек программасы билгеләдек. Кызганыч, Молдова хакимияте безне курергә теләмәгән затлар дип белдерде һәм ил чиген узарга рөхсәт итмәде, – дип белдерде Рөстәм Миңнеханов Кишинев аэропортында яздырылган видеоязмада.

Гагаузия – Молдованың көньягындагы автоном төбәк. Аларның күбесе – православие динендәге төркиләр. Гагаузлар 1800 нче елларда Госманлы төрекләренең эзәрлекләүләреннән качып, хәзерге Молдова килеп урнашкан, дип фаразлана. Гагаузия Молдованың хәзерге Президенты Майя Санду режимын тәнкыйтьли. Алар Россия белән берләшү яклы.

Виктор Петров Рөстәм Миңнехановка үзе катнаша алмаган форумнан видеоязма төшереп җибәрде. «Рөстәм Нургалиевич, Гагаузиядә сезне хөрмәт итәләр һәм яраталар. Бер-беребез белән ирекле рәвештә очраша, аралаша торган вакыт килеп җитәчәк дип ышанам. Моны озак көтәсе калмады», – ди ул мөрәҗәгатендә. Татарларга аңлаешлы итеп, үз туган телендә: «Татар халкы – безнең кан туганнарыбыз», – дип тә өстәде. Бу вакытта форумда катнашучылар Молдова, Россия һәм Татарстан әләмнәрен җилфердәтеп, дәррәү: «Рәхмәт!» – дип кычкырды.

Россия Дәүләт Думасына Татарстаннан сайланган депутат Олег Морозов фикеренчә, Молдованың әлеге кыланмышы аерым бәя бирүне таләп итә.

– Бу ил – НАТО әгъзасы да, Европа Берлегенеке дә түгел. Аны беркем дә санкция кертергә мәҗбүр итмәде. Әмма аның бик тә Вашингтон һәм Брюссельне яклыйсы килгән. Бик тә Рим папасыннан да изгерәк буласы килгән. Бу – безгә ачык сигнал, – ди Олег Морозов. – Кеше күрерлек итеп икътисадый сабак бирергә кирәк! Молдова моңа, һичшиксез, лаек!

Фикер

Марат БӘШИРОВ, сәясәт белгече:

– Бу турыдан-туры АКШка бәйле. Америка Татарстан Рәисен санкцияләр исемлегенә кертте. Шуңа күрә хәзер, Рөстәм Миңнеханов артык сүз әйтмәсен дип, чик куярга тырышалар. Ул әйтергә мөмкин булган сүз чынбарлыкны күрсәтеп бирә алганлыктан, Татарстан Рәисенә каршы административ чаралар күрәләр. Әмма сүзне санкцияләр белән генә чикләп булмый шул. Бүген интернет бар. Без монарчы халыкара кануннар гамәлдә булган, алар үтәлгән җәмгыятьтә яшәдек. Бүген исә бу халыкара кануннар барысы Көнбатыш, шулай ук Япония, Австралия, Көньяк Корея кебек илләр тарафыннан юкка чыгарылды. Шул рәвешле тотрыклылыкның нигезе бетерелде. Без халыкара кануннарга таянып, хокукларыбыз якланачагына ышана идек. Бүген алай түгел. Шуңа күрә федераль үзәк әлеге кануннар юкка чыгарылу турында белдерергә тиеш. Миллионлаган кешенең тынычлыгы, киләчәккә ышанычы нәкъ менә Америка тарафыннан юкка чыгарыла.

Андрей БОЛЬШАКОВ, КФУдагы халыкара мөнәсәбәтләр институтының кафедра мөдире, сәяси фәннәр докторы:

– Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка Кишиневта очкычтан чыгарга да рөхсәт итмәделәр. Югыйсә ул Молдовага «Халыклар дуслыгы конгрессы»ннан алган рәсми чакыру буенча барды. Шуңа күрә кабул итүче якның үз-үзен болай тотышы ким дигәндә бик сәер. Молдовада демократия, ирекле кыйммәтләре турында сөйләргә бик яраталар. Чынбарлыкта исә бу сүзләр дөреслеккә туры килми булып чыкты. Дипломатик беркетмә, кеше, халыкларның хокуклары дорфа рәвештә бозылды. Гагаузлар – элек-электән төрки татарлар белән элемтәдә торучы халык. Ни өчен халыкларның бер-берсе белән аралашу хокукы бозыла? Бу 2022 елда Украина кризисына карата нейтралитет белдергән Молдова хакимиятенә карата зур сорау уята. Сәяси иктан караганда, Россия Молдовага каршы тиешле җавап бирәчәк, дип өметләнәм.

minleshoz.tatarstan.ru

Урманнарга юл ябык

Сак бул!

Республикада янгын куркынычы зур! Урманчылар да, коткаручылар да чаң суга. 17 апрельдән 10 майга кадәр урманнарга керү бөтенләй тыела. Шулай ук бу вакытта учак ягарга да, анда нидер пешерергә дә ярамый. Чикләү вакытында тәртип бозучыларга штрафлар да каралган.

Бер җиңел сулар өчен, янгыр кирәк! Әлегә республикада явым-төшем күренми. Урманчылар борчуда. Янгынны булдырмау өчен ниләр генә эшләсәләр дә, бар ышанычлары кешеләрдә. Алар сак булса, янгынны булдырмый калачаклар. Бу хакта Министрлар Кабинетында узган очрашуда Татарстанның урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров сөйләде.

Министр иң элек урман хуҗалыгында башкарылган эшләргә тукталды. Быел урманда утырту эшләре 12 апрельдә үк башланган. Көздән үсеп китә алмаган агачларны алыштырганнар, киселгәннәре урынына яңасын утыртканнар.

– 2019 елдан башлап урман фондында мондый эшләр «Экология» илкүләм проектының «Урманнарны саклау» федераль проекты кысасында башкарыла, – диде ул. – Авыл хуҗалыгы җирләрендә дә агачлар утыртыла. Азнакай чикләрендә быел 1708 гектар урман утыртачакбыз. Шулай итеп, 2023 елда яңартасы һәм утыртасы мәйданнар 5322 гектарга җитә.

Министр утырту турында сөйләгәндә республикада җитештерелә торган үсентеләргә дә тукталды.

– Бездә ел саен 34 миллионнан артык стандарт утырту материалы үстерелә. «Хәтер бакчасы», «Урманны саклыйк» һәм «Татарстанның чиста урманнары» табигатьне саклау акцияләре узып тора, – ди министр. – 29 апрельдән «Хәтер бакчасы» халыкара акциясе башланып китә. Ул Бөек Җиңүнең 78 еллыгына багышланачак. Чара Татарстанның һәр районында, Казан янәшәсендә өч урында үтәчәк. Барлыгы 1 миллионга якын үсенте утыртылыр дип торабыз.

Урманнарда чистарту акциясе дә башланды инде. 17 апрельдән «Татарстанның чиста урманнары» дип аталган чарада һәркем катнаша ала. Аны ике тапкыр үткәрәләр: язын һәм көзен. Максат бер – урманны чүп-чардан, корыган ботаклардан арындыру. Әлеге чара кысасында узган ел урманнардан 3,8 мең кубометр каты көнкүреш калдыклары, 5,2 мең кубометр корыган агач, чыбык-чабыклар чыгарылган.

Чистарынуның максаты да аңлашыла: чүптән арындырып, урманнарны янгыннан саклауга кирәк! Очрашуда министр янгын темасына күп сөйләде. Сөйләмәслек тә түгел. Узган үк әйтеп тора. Әле шушы көннәрдә генә Лениногорск районында яшәүче бер ир үләнгә ут төрткәндә тотылган.

– Барыбыз да белә, янгын куркынычы зур. Быел урманнарда янгынга каршы режим 24 көнгә иртәрәк кертелде. Барысы да һава торышына бәйле. Урманчылар да көн-төн кизү тора. Җәяүләп тә йөрибез, күктән дә күзәтәбез, махсус техникалар белән дә тирә-якны әйләнеп чыгабыз. Шул рейдлар вакытында Алабуга урманчылары бер ир-атны күреп ала. Баштарак җәяүләп барган иргә игътибар итмиләр. Соңрак исә иелеп нидер эшләвен күрәләр. Озак та үтми, артыннан үләнгә ут каба. Куып җитеп, ирне туктаталар. Баксаң, хатыны белән ачуланышкан икән, – ди министр.

Исегезгә төшерәбез: шушы көннәрдә генә үләнгә ут төрту аркасында күпме кешеләр ызын күрде, йортсыз калучылар да бар. 14 апрельдә Мамадыш районында 15 гектар җирдә үләнгә ут кабып, аннан соң йортка урмәләп, бар каралты-кураны чолгап алуын да ишеткәнсездер инде. Республикада бүгенгә коры үләнгә ут кабуның 528 очрагы теркәлгән инде. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсе җитәкчесе Максим Трущин әйтүенчә, быел, янгын сүндерәм, дип, үзенә зыян китергән кешеләр дә бар. Кулларын, аякларын, тәннәрен пешерү очраклары да теркәлгән.

– 17 апрельдән 10 майга кадәр Татарстанда чүп ягу, шашлык пешерү бөтенләй тыела. Янгын куркынычсызлыгы режимы кертелгән вакытта урманга якын торган 116 торак пукт, 75 бакчачылык ширкәте, 84 балалар ял лагерьлары аеруча контрольгә алынаҗак, – ди ул. – Бер генә җирдә дә учак кабызырга, каты көнкүреш калдыкларын, коры үлән һәм чүп-чар яндырырга ярамый. Моннан тыш, табигатькә ял иткән вакытта, шулай ук бакчачылык ширкәтләре территориясендә ачык утта ризык әзерләргә рөхсәт ителми. Пиротехника куллану да тыела.

Май бәйрәмнәре үзенекен итәр. Тыелган дип тормаслар, халык табигатькә чыгар. Мондый чорда учак яксаң, ни була?

– Без дә, коткаручылар да инде рейдларга чыга башладык. Халыкны кисәтәбез. Ут белән шаярырга ярамаганын исләренә төшерәбез. Урманга якын торган җирләрдә махсус полосалар ясауны, тирә-якны уттан саклауны сорыйбыз, – ди министр.

Сан

Янгын куркынычсызлыгы режимы кертелгән вакытта урманнарда кагыйдә бозган кешеләргә **40** меңнән **50** мең сумга кадәр, вазыйфаи затларга – **60** меңнән **90** мең сумга кадәр, юридик затларга **600** меңнән **1** миллион сумга кадәр штраф салыначак.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

Тизлекне арттырасы

Торак төзелеше темпларын киметмәскә, тармакка яшь белгечләрне җәлеп итәргә. Мәскәүдә узган Инфраструктураны үстерү буенча стратегик сессиядә шул хакта сөйләштеләр. Утырышта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Россия Премьер-министры Михаил Мишустин, утырышны ачып, тармак уңышларын барлады. Аның сүзләре белән әйтсәк, чикләүләргә карамастан, тармак үсештә. Моны саннар да дәлилли. Әйтик, соңгы өч елда гына да башкарылган эшләр күләме 15 процентка арткан. Былтыр файдалануга тапшырылган йортлар күрсәткече дә рекордлы иде. Бу – 3,5 млн гаиләгә торак шартларын яхшыртырга мөмкинлек бирелгән дигән сүз.

Михаил Мишустин әйтүенчә, шушы темпны саклау да мөһим. Моның өчен тармакны көчле белгечләр белән баету да кирәк. Тагын бер мөһим юнәлеш – логистиканы камилләштерү. Бу җәһәттән ул М12 трассасының Мәскәүдән Казанга кадәр булган өлешен былел (вакытыннан алда!) кулланылышка тапшыруга җыенуларын әйтте.

– Биш еллык юл эшчәнлеге планын финанслауның гомуми күләме 13 трлн сумга якын тәшкил итә. Бу – җитди матди чаралар. Хәзер безгә билгеләнгән бар нәрсәне әзлекле һәм, иң мөһиме, нәтиҗәле итеп тормышка ашырырга кирәк. Без бу юнәлешне даими контрольдә тотачакбыз. Алда торган эшләрнең шактый күләме төбәк юлларын яңартуга да бәйле. Россия субъектларына мондый максатларга 140 млрд сумга якын казна кредитлары бирү турында карарлар кабул ителде, – диде Михаил Мишустин.

«АКЧАЛЫ БИШ» КИРӘКМЕ?

«5ле» өчен – акча. Дәүләт Думасында депутат Анна Скрозникова әнә шундый тәкъдим белән чыккан. Акчаны исә балаларның кулына бирергә түгел, «Пушкин картасы»на күчерергә киңәш итә. Укытучылар арасында әлеге фикерне тузга язмаган дип санаучылар да бар. «5ле» ул – үзе бүләк, диләр. Акча белән уку теләген арттырып булырмы?

Анна Скрозникова белдерүенчә, «Пушкин картасы» яшьләрдә мәдәниятка карата кызыксыну уята. Шуны исәпкә алып, депутат «5ле»ләр өчен түләргә һәм акчаны чирек ахырында электрон журнал аша «Пушкин картасы»на күчерергә тәкъдим итә. Башта аны тәҗрибә буларак сынап карарга мөмкин.

Балтач районындагы Пыжмара мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы Ислам Әсхадуллин әлеге яңалыкны ишеткәч, бик сөенгән. Егет һәрбер хезмәт бәяләнергә тиеш дип саный. Нурлат районының Кулбай Мораса мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы Әлфинә исә, моның ике ягы бар, ди. Беренчедән, тырышып укырга этәргеч бирсә, икенчедән, коррупциягә китерергә мөмкин. Казандагы «Адымнар» күптелле белем бирү мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы Нариман Вилданов фикеренчә, яхшы укырга этәргеч бирү өчен уку йортлары болай да бүләкләр, сертификатлар, медальләр тәкъдим итә ала. Ә «5ле» өчен түләү белән шаярырга кирәкми.

Журналист, ике бала әнисе Эльвира Мозаффарованың кызы сыйныфташлары белән «Билге өчен мегабайт»лар проектында катнашып, бүләк откан.

– «Теле-2» операторының махсус кушымтасы бар. Шуның аша һәр «5ле» өчен өстәмә интернет бирелә. Кызым шуннан файдалана. «5ле»ләрен санап бармый, әмма яхшы укырга тырыша. «Пушкин картасы»ның файдасы бар. Балалар күбрәк киного йөрергә ярата. Яңа кызыксындыру чарасы уйлап табылса, бик әйбәт бит, – ди Эльвира Мозаффарова.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Мамадыш районының Түбән Ушма мәктәбе укучыларга «2ле» куймавы белән аерылып тора. Үзенчәлекле мәктәптә бу уңайдан ни уйлыйлар икән?

– «2ле» куймау – бер мәсьәлә, ул йомшак укучыны шәхес буларак саклап калырга ярдәм итә, ә акчалы «5ле» – бөтенләй башка очрак. Бала өчен яхшы билге болай да бик кыйммәт. Аны акчалы итү яхшыга илтмәс. Укучы билгегә түгел, белемгә омтылырга тиеш, – ди башлангыч сыйныф укытучысы Әнисә Миннәхмәтова.

Фикер

Миләүшә ХӘЙРУЛЛИНА,
Биектау районы Дөбъяз мәктәбенең рус теле укытучысы:

– «Пушкин картасы» белән укучылар Камал, Тинчурин театрларына, районда уза торган чараларга бара. Әнә театры да безгә еш килә. Кирәк вакытта бик әйбәттер ул. Ә менә «5ле»гә акча түләү турында ишеткәч, аптырап калдым. Дөрес юлдан барамы икән болар? һәр укытучының билгесе аерылырга мөмкин. Аны барлык күрсәткеч буенча куеп бетермәве дә бар. Кайчак, бигрәк тә малайларга кечкенә генә уңыш өчен дә, күңеле булсын дип, «5ле» куясың. Аның бит әле шул яхшы турында да уйларга кирәк.

Чулпан Ярулллина фикеренчә, Россиядә укучыларга акчаны «5ле» өчен түли башласалар, укучыларга үз фикерен әйтү мөмкинлеге калмаячак. «Әгәр бу тәкъдим кабул ителсә, укучы гына түгел, әти-әни тарафыннан болай да «типкәләнүче» укытучы тел кысрыкланып, мыскыллаыып бетәчәк», – дип борчыла педагог.

Рус теле һәм әдәбияты укытучысы Наилә Садриева мәктәптә билге өчен нинди да булса акча түләүгә каршы. «Билге үзе этәргеч бит инде ул, ничек аның өчен акча алырга мөмкин?! Кемнеңдер сәләте бар, ул «4» һәм «5»ле»гә укый. Сәләте юк икән, түбәнрәк билге ала. Укучыларны матди яктан бүлүгә кайтып кала түгелме соң бу?» – ди ул.

Алабуга районы укытучысы Айгөл Галимова да депутат фикере белән килешми.

– Башта ришвәтчелекне бетерергә кирәк. «5ле»ләрне турә баласына куйдыра башлаячаклар. Укучыларның күбесенә берни кирәкми. «2ле» белән дә куркытып булмый. Чөнки мәктәптә «3ле» куеп чыгарып җибәрәчәкләрен беләләр. «5ле»гә укучы барыбер тырышачак: хет акча түлә, хет түләмә, – ди Айгөл Галимова.

Сәрия МИФТАХОВА

ЯШӘП ТУЮ

ЯШҮСМЕРЛӘРНЕ ҮЗ-ҮЗЕНӘ КУЛ САЛЫРГА НӘРСӘ ЭТӘРӘ?

Без әле кая барабыз?

«Классташларым яратмый, абыем кыйный, җавапсыз мәхәббәт кичерәм. Үләсе килә!», «Барысы да туйдырды! Яшисе килми!», «Фотосурәтемә карыйм да ямьсез булуымны аңлыйм. Мин яшәргә тиеш түгел!» Ышанмаган җирдән ышанырга туры килер: популяр социаль челтәрдәге үз-үзенә кул салырга теләүчеләрнең төркемендә яшьләр язып калдырган сүзләр бу! Суицид турында уйланучыларны соңгы чиккә этәргән сәбәпләрнең берничәсе, әмма еш очрый торганнары шушылар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Үлемдә мәгънә күрәм»

М. үзен кая куярга белмәгәнгә, фикердәш таба алмаганга күрә, социаль челтәрләрдәге шундый төркемнәргә кушылып, күңелен бушатырга тырыша.

– «Барысы да яхшы буласына ышан» дигән юк-бар киңәшләр язсалар да, чарасызлыктан, бушанасым килә. Берничә ай дәвамында үз-үземә кул салу турында уйланам. Әмма моның сәбәпләрен белмим… – ди кыз. – Психологка баруның мәгънәсен тапмыйм. Юк-бар белән башыңны катырасың, ата-анаң ашата, эчертә, тәэмин итә бит сине, диюдән башка сүз ишетмәячәкмен. Хәлемә килгәндә, төшенкелек, өметсезлек хисләрен кичерәм. Уңай эмоцияләр кичермәвемә шактый инде. Көн дәвамында арыганлык хисе баса, уянасы килми. Эчке бушлыктан кала бернәрсә дә тоймыйм бугай.

М. әти-әнисе белән мөнәсәбәтләрнең дә шәптән түгеллеген яшерми. «Мин санап үткәннәр алар өчен – буш сүз. Минемчә, алар миңа карата бернинди дә ярату хисе кичерми. Бөтен нәрсәне дә ата-ана бурычы хакына гына эшли», – дигән фикер оялаган яшүсмердә.

М. мәктәптә дә әллә ни аерылып тора торган кеше түгел икән. Бер сүз белән әйтсәк – ялгызак. Дуслары да, кемнәр беләндер дуслашырга теләге дә юк. Әмма начар укымый, «4ле», «5ле» билгеләре белән сөендерә.

– Үләсе килү теләге әти-әни белән әрләшкәч яисә мәктәптән кайткач барлыкка килә. Социаль челтәрләрдә начар хәбәр күрсәм, бу теләк көчәя генә, – ди ул. – Мин барысын да үзгәртергә телим, ләкин миннән башка бу беркемгә дә кирәкми, шуңа күрә мәгънәне үлемдә генә күрәм.

Куркыныч статистика

2020–2022 елларда Татарстанда балигъ булмаган балалар арасында суицид очраклары кисәк арткан. Статистиканың куркыныч булуын Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Ирина Волынец әйткән иде.

Аның сүзләренә караганда, 2020 елда шундый 11 очрак теркәлсә, 2022 елда үз-үзенә кул салучы яшүсмерләр 22гә җиткән. Соңгы биш елдагы иң зур күрсәткеч бу. Өстәвенә яшь чикләре дә үзгәреш кичергән: элек 13 яшь булса, хәзер инде кырын уйлар 11 яшьлек балаларның да башына керә. 2022 елдагы суицид очраклары, нигездә, 16–17 яшьлекләргә туры килә. 13 яшькә кадәргеләр арасында алты суицид очрагы теркәлгән.

Республиканың балалар омбудсмены Ирина Волынец фикеренчә, яшь буынның үз-үзенә кул салу сәбәпләре гаиләдәге низагларга, аңлашылмаучылык, ялгызлыкка бәйле. Берничә ел элек үз-үзенә кул салуны, нигездә, тулы булмаган гаиләләрдәге балалар башкарса, хәзер бу – имин саналган гаиләләрнең дә баш бәласе.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ЯРДӘМ КУЛЫ

Суицидны булдырмый калу мөмкин, ди белгечләр. Бу эш беркайчан да уйланылмыйча башкарылмый. Аңа хас билгеләр дә, сәбәпләр дә бар. Бик еш кына үлем-китемнәр – игътибарсызлыгыбызның аяныч җимеше.

Ничек булышырга?

✓**Тыңларга.** «Була торган хәл», «Уза ул, бетә ул» дияргә түгел. «Мин сине тыңлыйм» дип, уй-кичерешләрне сөйләргә мөмкинлек тудырырга кирәк.

✓**Фикер алышырга.** Мәсьәләне ачык рәвештә, уртага салып сөйләшү – нәтиҗәле ысул. Ул борчылу хисен дә баса. Бу темадан качу – хәлдән чыгу юлы түгел.

✓**Игътибарлы булу.** Вак-төякләргә, кәеф үзгәрешләренә, кешенең үз-үзен тотышына.

✓**Өмет уяту.** Төшенкелеккә бирелгән кешенең еш кына таяныр ноктасы булмый. Мондый чакта үз кыйммәтләреңне көчләп тагарга түгел, ә аңлаучы кеше булырга кирәк.

Сан

➤Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы (ВОЗ) мәгълүматларына ышансаң, дөньяда ел саен 800 меңләп кеше үз-үзенә кул сала. Башкача әйткәндә, һәр 40 секунд саен бер кеше якты дөнья белән хушлаша.

➤Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе мәгълүматларына караганда, 2022 елда балалар арасында 90 суицидка омтылыш теркәлгән. 2020 елда бу күрсәткеч 53 булса, 2021 елда – 77.

➤Татарстанда, Башкортстан белән беррәттән, Идел буе федераль округында балалар арасындагы суицид очраклары саны аеруча күп теркәлә.

БАЛАНЫ САКЛЫЙСЫ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Кызамыкка каршы прививка, иң беренче чиратта, балаларга ясалырга тиеш, дип саный ул. Ник дигәндә, алар бу чирне авырданрак уздыра. Авырып терелгәннән соң да җитди өзлегүләр күзәтелергә мөмкин.

– Кызамык белән авырганнан соң, өлкәннәрдә пневмония башланырга мөмкин. Балалар өчен хәлләр тагын да аянычрак тәмамлануы бар. Ник дигәндә, кызамык аркасында баланың баш мие тулысынча ялкынсынырга (панэнцефалит) мөмкин. Иң куркынычы шул: әлеге чир бала кызамык белән авырып терелгәннән соң биш еллап вакыт узгач кына пәйда була. Бала начар укый, баш авыртудан зарлана башлый. Авыру торган саен көчәя генә. Ата-ана эшнең нидә икәнен аңлый алмыйча тилмерә. Ахыр чиктә, бала инвалид ук калырга мөмкин. Ул нәкъ инсульт кичергән кеше кебек хәрәкәтләнә, сөйләшә алмый башлый, башы эшләми. Шуңа күрә балаларга иң беренче чиратта кызамыкка каршы прививка ясалырга тиеш, – дип кисәтә Дмитрий Лопушев.

11 нче номерлы шәһәр балалар хастаханәсе педиатры, Татарстанның атказанган табибы Гөлназ Азизова сүзләренә караганда, кызамык күбрәк 2–5 яшьлек балалар арасында ачыклана.

– Кызамык еш кына гадәти ОРВИ кебек башлана. Шуңа күрә баштарак табиб аны төгәл ачыклап бетермәскә дә мөмкин. Беренче көннәрдә бала ютәлли, тамагы авырта, борынга томау төшә. Аны бизгәк тотарга, күзенә конъюнктивит чыгарга да мөмкин. Кызамык башлануның дүртенче көнендә тәнгә кызыл тимгелләр чыга башлый. Ул тиз арада тарала, артканнан-арта бара. Баштан алып аяк бармакларына кадәр кызыл тимгелләр чыга. Бала коңгырт кызыл төскә керә. Тәнгә тимгел чыкканда баланың температурасы 40 градуска кадәр күтәрелә. Ул яктылыктан курка башлый. Дүрт көн дәвамында баланың температурасы бик югары була. Аннары тимгелләр акрынлап кими, – ди табиб. – Тимгелләр бетеп, баланың хәле тиз арада уңайланса, ярый да. Әмма авырып терелгән балада еш кына бик җитди өзлегүләр дә күзәтелә. Андый чакта менингит башланырга, аякларны көзән җыерырга мөмкин. Кызамык бөерләргә дә бәрә. Анысы бигрәк тә куркыныч. Ник дигәндә, ул үлемгә үк китерергә мөмкин. Балада кызамык билгеләре күзәтелүгә, кичекмәстән табиб чакыртырга кирәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КАН БИРҮ ҖАН БИРҮ ТҮГЕЛ

Игелекле гамәл

Кеше гомере кыл өстендә, диләр. Кайбер очракларда аны саклап калу табиблардан гына түгел, донорлардан да тора. Статистика буенча, һәр өченче кеше үз гомерендә кан салдыруга мохтаҗ. 20 апрель – Илкүләм донор көне уңаеннан йөрәк кушуы буенча кеше гомерен саклаучылар белән сөйләштек.

Латинчадан тәрҗемә иткәндә «донор» сүзе «бүләк итү» дигәнне аңлата икән. Бу очраклы түгел, чөнки донорлар чын мәгънәсендә кешегә тормыш бүләк итә. Илебездә ел саен миллион ярымга якын кеше (көненә – дүрт мең) кан салуга мохтаҗ. Республика кан үзәге көн саен йөзгә якын донорны кабул итә. Бу хакта үзәк табибы Елена Төхвәтуллина әйтте.

– Кан һәрчак кирәк. Плазма зарарланган кан тамырларын, бавыр авыруларын дәвалауда, кан китүне туктату, пешүләр очрагында файдаланыла. Кан катлаулы операция кичергән кешегә, бәби табучы хатын-кызга, яман шеш белән авыручыларга, юл һәлакәтенә эләккән, күп кан югалткан кешеләргә зур ярдәм бирә ала, – диде ул.

Бөтен кеше дә кан тапшыра алмый. Донор булу өчен кешенең авырлыгы 55 килограммнан кимрәк булмаска, тән температурасы 37 градустан, йөрәк тибеше минутына 50–100дән артмаска тиеш. Кан бирергә килүчегә медицина тикшерүе үткәрелә. Гомуми кан анализыннан гемоглобинны, ялкынсынулар юкмы икәнен карыйлар. Шулай ук донорның ВИЧ-инфекция һәм В, С гепатитлары белән авырмавы, хроник чирләре булмавы мөһим.

«Ул вакыттагы хис-кичерешләрем әле дә күңелемдә саклана». Беренче тапкыр кан тапшыруын «Мактаулы донор» Надежда Мөхәммәтова әнә шулай дип искә ала.

– Беренче тапкыр студент чакта төркемебез белән кан бирергә бардык. Ул вакыттагы хис-кичерешләрем әле дә күңелемдә саклана. Бераз хәлсезләндем, башым әйләнде, ләкин бу гына мине туктатып калмады. Кешеләргә ярдәм итү, үз бурычымны үтәү хисен бернәрсә белән дә чагыштырып булмый, – ди ул. – Хәзер бик күп юл һәлакәтләре булып тора, катлаулы операцияләр ясала. Күп кешегә кан кирәк. Кешенең сәламәтлеге, башкаларга булышу теләге бар икән, әлбәттә, ул моны эшләргә тиеш. Минем тромбоцитларны (кан күзәнәкләре) яман шеш белән авыручыларга салган очраклар да булды. Минем каным башка кешеләргә яшәргә булыша икән, бу мине бәхетле итә. Кан тапшыру – җаваплы эш. Сыйфатлы кан бирү өчен ачык һавада күп йөрергә, файдалы тукланырга, яхшы йокларга кирәк.

КФУ студенты, «Игелекле Татарстан – 2022» премиясе җиңүчесе, «Ел волонтеры» Аммар Хөсәейн, кан тапшыргач, яңа көч, энергия өстәлгәндәй була, ди.

– Мин йогышлы авырулар хастаханәсендә реанимация бүлегендә эшлим. Бер юлы анемия булган хатын-кызны китерделәр. Без аңа 3 ай дәвамында 38 тапкыр кан салдырдык. Башка берәүнең гомерен саклап калу өчен үзеңнең бер өлешең белән бүлешү, бүтәннәргә яшәү мөмкинлеге бирү – бик мөһим. Минемчә, донор булу һәр кешегә кирәк. Без яшь, безнең моның өчен барлык мөмкинлекләр бар. Булдыра алганча кешеләрнең гомерләрен саклап калырга омтылырга кирәк, – диде ул. – Кан тапшыргач, яңа көч, энергия өстәлгәндәй була. Чөнки организмда яңару процессы башлана. Кан чистара, организм ныгый. Авыруларга да сирәк бирешә башлыйсың. Моның бернинди куркынычы да юк. Кеше организмында һәрвакыт запас бар.

74 яшьлек мактаулы донор Рәйсә Сафина әле яшьлегендә, сыер савучы булып эшләгәндә кан тапшыра башлаган.
– Фермада 40 ел эшләдем. Шунда эшләгән дәвердә кан тапшырдым. Район үзәгенә барып бирә идек, авылга да килеп алганнары булды. Кан бик кирәк кешеләргә тиз генә чакыртып алганнары да булды. Авыр кичермәдем, хәлсезләнү, баш әйләнүләр булмады. Йөгерә-йөгерә эшли идек, – ди мактаулы донор. – «Мактаулы донор» исемен 1995 елда алдым. Елына бер тапкыр премия бирәләр. Бәлки, минем кан меңләгән кешенең гомерен саклап калгандыр. Мактаулы донор булуым белән горурланам.

Республика кан үзәге китергән мәгълүматлар буенча, Татарстанда даими рәвештә 33436 мең кеше кан тапшыра. Шуларның 70 проценты – ир-атлар, 30 проценты – хатын-кызлар. Кан бирүчеләр арасында күбесе – яшьләр (20 яшьтән 29 яшькә кадәр – 46 процент).



Ил тарихы

Татарстан Рәисе Администрациясе җитәкчесе, Татарстанның «Динамо» физик культура һәм спорт җәмгыяте рәисе Әсгать СӘФӘРОВ «Динамо» Бөтенроссия җәмгыятенең 100 еллыгы белән котлады.

«Барлык спортчыларны, тренерлар, хезмәткәрләр, спорт ветераннары, яшь спортчылар һәм җанатарларны «Динамо» Бөтенроссия җәмгыятенең 100 еллыгы уңаеннан котлыйм!

Җәмгыять үзенең бер гасырлык «гомере» дәверендә бик күп традицияләр булдырган, искитмәле спорт казанышлары, күренекле шәхесләр бүләк иткән. «Динамо»ның Лев Яшин, Аркадий Чернышев, Людмила Пахомова, Александр Горшков, Николай Тихонов, Вячеслав Веденин, Александр Карелин кебек әгъзалары, үз исемнәрен илебез һәм дөнья спорты тарихына кертүгә ирешеп, күп буыннарга үрнәк булып тора.

«Динамо»ның Татарстан вәкилләренең дә гомуми җиңүләргә үз өлешен кертүен билгеләп үтү күңелдә аеруча зур канәгатьлек хисләре уята. Безнең динамочылар иң зур ярышларда, хәтта Олимпия уеннарында да зур уңышларга ирешкән. Фехтование осталары Наилә Гыйләҗева, Ольга Князева һәм Валентина Никонова, чаңгычылар Фёдор Симашов, Ольга Данилова, Андрей Дементьев, Максим Вылегжанин, штангачы Николай Колесников, җиңел атлетика остасы Гөлнара Галкина-Сәмитова, стендка ату осталары Светлана Демина, Василий Мосин, волейболчылар Екатерина Гамова, Максим Михайлов, боксер Имам Хатаев, дзюдо остасы Таһир Хәйбуллаев һ.б. исемнәрен бөтен дөньяда беләләр. Волейбол, чирәм хоккее һәм туплы хоккей буенча безнең «Динамо» командалары спорт елъязмасына үзләреннән байтак кына истәлекле сәхифәләр калдырды.

Барлык динамочыларга нык сәламәтлек, бетмәс-төкәнмәс көч-куәт, оптимизм рухы һәм, әлбәттә инде, яңа җиңүләр телим! Динамочыларның Россиянең данлыклы спорт тарихы елъязмасына әле тагын бик күп җиңүле сәхифәләр өстәячәгенә ышанам! Башкача була да алмый, чөнки ил тарихы – «Динамо» тарихы», – диелә котлауда.

«Динамо»лы тормыш

Әхмәт Нәбиуллинның шәхси архивыннан

«Динамо» барлыкка килгән көн! 18 апрель Бөтенроссия физкультура-спорт җәмгыяте үзенең 100 еллык юбилеен билгеләп үтә. Данлы җиңүләр тарихы елъязмасында Татарстан динамолыларының да өлеше зур. Шундый исемнәрнең берсе – Әхмәт Нәбиуллин. «Динамо» хәрәкәте ветераны яраткан клубына 44 елын багышлаган.

«Динамо»ның күренекле җиңүләре һәм легендар исемнәре ил, дөнья спорты тарихына мәңгегә уелып калачак. 100 ел эчендә динамолылар спортның барлык төрләрендә диярлек якты эз калдырган, миллионлаган кешедә спортка мәхәббәт тәрбияләгән.

Әхмәт Нәбиуллин мәктәптә укыган елларда ук спорт белән җенләнә башлый. Әлеге мавыгу тора-бара рухи ихтыяҗга әверелә һәм булачак спортчыны «Динамо»га китерә. Аны спортның авыр һәм җиңел атлетика төрләре кызыксындыра. Ул – йөгерү, спорт йөрүе, чаңгыда шуу, марафон, кул көрәше, гер күтәрү, турникта тартылу буенча спорт мастеры. Дистәләгән республика, Россия, Европа күләмендәге ярышларда катнашып, спортның әлеге төрләре буенча яулаган җиңүләре күпләрне таң калдырырлык.

– Мин гомерем буе «Динамо»да. Бу – минем өчен зур горурлык. Ничә ел эчендә без Россия, Европа чемпионнары булдык, югары дәрәҗәләргә ирештек. Динамолыларны һәрвакыт рух ныклыгы, дисциплина аерып торды. Татарстан спортчылары һәрвакыт беренчеләр рәтендә булды. Татарстандагы «Динамо» оешмасының рәисе Әсгать Сәфәровка үз клубына тугрылыгы өчен рәхмәт белдерәм, – ди ветеран спортчы. – Элек без үзебезне бер спорт төре белән генә чикләмәдек, төрле дисциплиналарда чыгыш ясадык. «Динамо» җитәкчелеге профессиональ спортны гына түгел, массакүләм спортны да үстерә. Без – ветераннарга да зур игътибар бирә.

Әхмәт Нәбиуллин күп еллар профессиональ спортчылар белән шөгыльләнгән.

– Алар белән эшләү өчен син үзең дә профессиональ спортчы булырга тиеш. Телләрен белергә кирәк. Башкача булмый, – ди спортчы.

Әле хәзер дә кимен куймый ул. Атказанган спорт остасы, дөнья, Европа һәм СССР чемпионы бүген җиңел атлетика буенча Татарстан җыелма командасы составында чыгыш ясый. Әле күптән түгел генә ветераннар арасында җиңел атлетика буенча Россия чемпионатында чыгыш ясап, эстафета йөгерешендә өченче урын яулаган. Спорт чараларын оештыруда ярдәм иткәне өчен спортчы Чаллы шәһәренең «Динамо» рәисе урынбасары Александр Питиримовка рәхмәтен белдерде.

– Спорт көчле, артка чигенми торган, максатчан кешеләрне ярата. Спортта бирешмәүчеләр тормышта да бирешмәячәк. Ул физик яктан гына түгел, рухи яктан да тәрбияли, – ди «Динамо» ветераны.

Әхмәт Нәбиуллин «Динамо» җәмгыятенә киләчәктә дә уңышларга ирешүен һәм һәрвакыт беренче булуын теләде.

Ләйсән САФИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы урынбасары **Шәймәрданов** Илсур Васил улына **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе **Хисматуллин** Ришат Сәхәп улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

«Чүпрәле район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең Матак ветеринария участогы ветеринария фельдшеры **Ахметшин** Фиркат Мөбәрәкша улына **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«ВОСТОК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте сыер савучысы (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Ибраһимова** Рушания Гаяз кызына **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«ИГЕНЧЕ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең баш зоотехнигы (Татарстан Республикасының Саба районы) **Вәлиев** Марс Фәрит улына **«Татарстан Республикасының атказанган зоотехнигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Арбор» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Ульданов** Нурулла Гарифулла улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

КОНТРАКТ БУЕНЧА ХӘРБИ ХЕЗМӘТ

РФ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ БЕЛӘН КОНТРАКТ ТӨЗЕГӘЧ, БЕР ТАПКЫР ТҮЛӘНЕЛӘ:

195 000 сум

Махсус хәрби операциядә катнашкан өчен өстәмә түләүләр каралган

Хәрби комиссариатка мөрәҗәгать итү өчен:

8 (843) 221-44-52



Спорт

Кирәк чакта

22 апрельдә «Ак барс»ның өченче мәртәбә Гагарин Кубогын яулаганына тәгәл биш ел була. 2018 елда Татарстан башкаласында узган хәлиткеч матчта Казан командасы ЦСКА капкасына нибары бер алка кертеп, серияне 4:1 исәбе белән үз файдасына төгәлләде. 2023 елның апреле: «Ак барс» белән ЦСКА янә җиңү өчен көрәшә. Биш ел элек булган кебек, Зиннәтулла Билалетдинов уенчылары эшне янә җиңүдән башлады.

Дөрес, икесе ике команда болар. «Ак барс» ул җиңүдән соң Гагарин Кубогы финалына чыга алмый азапланды. Зиннәтулла Билалетдинов китеп, кабат үз урынына кайткан арада Казанга ике баш тренер килеп, берни майтара алмый китте. Составтагы үзгәрешләрне әйткән дә юк. ЦСКАга килеп киткән уенчылар күп булды. Әмма Мәскәү командасы өч сезон рәттән финалга барып җитеп, икесендә чемпион исемен яулады. Искиткеч күрсәткеч! Статистика менә нәрсә сөйли: Мәскәү уенчылары 2022 елның языннан бирле плэй-оффта бер генә серияне дә оттырмаган. Былтыр 4 һәм быел 3 көндәштән өстен чыкканнар. Шунысы да бар: кемгә генә каршы уйнамасыннар, беренче очрашуда һәрвакыт җиңүгә ирешкәннәр. Болар барысы да – Сергей Федоров җитәкчелегендә.

Шик юк: Мәскәү командасының остазы – яхшы белгеч. Заманында өчәр мәртәбә СССР чемпионатын откан һәм Стэнли Кубогын яулаган кеше. Дөнья чемпионатларында җиңгәне бар, Олимпия Уеннарында медаль оту серен белә. Тренер булып эшли башлаган елны ук Гагарин Кубогын яулады. Тик бер кимчелеге бар: моңа кадәр тренер буларак Зиннәтулла Билалетдиновка каршы чыкканы юк иде.

Конференция финалында СКАны тар-мар итеп, хәлиткеч уеннарда фаворит булып саналырга лаек күрелгән ЦСКА Казанда 1:4 исәбе белән оттырды. «Ак барс»ның алкаларын күпне күргән, кирәк вакытта көндәшне дә, үзен дә кызганмаучы Артем Лукоянов, 2018 елгы плэй-оффта иң күп алка кертүче булып танылган Станислав Галиев, НХЛ клубларының игътибарын җәлеп иткән Дмитрий Воронков һәм матч тәмамланырга 7 минут калып барганда 77 нче санлы уенчы Кирилл Адамчук биргән пас ярдәмендә 7 нче санлы һөҗүмче Кирилл Панюков кертте. Тимур Билалов бу сезонда иң яхшы капкачы булып саналырга лаек икәнен раслады. Сүз уңаеннан, Воронков тарихка да кереп калды. Ул яңа гасырда, ягъни 2000 елның 1 гыйнварыннан соң туган уенчылар арасында КХЛда беренче булып 50 алка кертте.

Юк, көндәш тә начар уйнамады. Статистикага ышансаң, хәтта күбрәк һөҗүм иткәннәр, капка турысына сугылган алкалары да күбрәк. Тик Зиннәтулла Билалетдинов командасы үз мөмкинлегеннән яхшырак файдалана алды. Беренче периодта көндәшләр өстен күренсә, икенчесендә уен «Ак барс» теләгәнчә, ягъни чал чәчле остаз көйләгәнчә барды. «Егетләр тырыша, алар әйткәнне яхшырак итеп үтәргә тырыша, – диде баш тренер матчтан соң һәм көндәшне дә мактарга онытмады. – Моңа кадәр плэй-оффта очрашкан командалар белән чагыштырганда, ЦСКАның уенчылары яхшырак, әлбәттә. Беркемне дә түбәнсетәсем килми, элеккегеләре дә әйбәт иде. Әмма ЦСКА – бик яхшы команда. Аларга каршы уйнау бик авыр».

Артем ЛУКОЯНОВ, «Ак барс» һөҗүмчесе:
– Башта сугыша башлыйсың да, калганы аннары күренә инде. Хәзер без – көндәшнең, алар безнең ничек уйнаганны белә. Нәрсәнедер алмаштырырга туры киләчәк. Чемпионга каршы уйныйсыбызны белдек. Авыррак, әлбәттә, әмма аларга каршы уйнап та, җиңеп тә булганны күрсәттек. Бары тырышлык белән генә дөрес уйнасак, нәтиҗәсе булачак.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

38 ЕЛ БУЕ СЫЕР САУГАН РУШАНИЯ ИБРАҺИМОВА:

«ЭШ СЕЗДӘН КУРКЫП ТОРСЫН!»

Авыл уңганнары

Заманында бик күпләр мәктәп бетергән дә фермага юл тоткан. Кул хезмәте, авыр күтәреп ташу, үзәкләргә үтәрлек салкында резин итекләр киеп йөрү дә, таңнан торып, тәмле йокыларны калдыру да куркытмаган. Шушы һөнәрне яратып гомер буе эшләгән алар.

Авылда ферма эшләп торуның никадәр кадерле булганын аңладык инде без. Ул чакта авыл өстенә исләр тарала. Тирес исе, малларга бирелгән башак исе, апара исе, сөт исе… Сыерларның мөгрәү тавышы. Моңлы бер җырга тиң булган икән бит алар! Шөкер, күп җирдә әле малкайларны саклап калдылар, хәтта ел саен баш санын да арттырып торалар. Бар да заманча хәзер. «Йолдыз», «Миләш», «Сандугач» кушаматлары урынына колакларында саннар булса да, сыерлары да шул ук, аларны яратып савучылары да әле «тегә» заманнан.

Кукмара районының «Восток» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятендә сыер савучы Рушания Ибраһимова, эшемне бик яратып башкарам, ди. Шушы көннәрдә аңа Татарстан Рәисе карары белән «Татарстанның атказанган терлекчесе» дигән мактаулы исем бирелде. Әлеге шатлыгын уртаклашып, тәбрик итәр өчен без аңа шалтыраттык. Рушания апа башта каушап та китте. Үзен шулай зурларлар дип көтмәгән дә ул. Җитәкчеләре хезмәтен күреп, мактаулы исемгә тәкъдим иткәннәр икән.

– Бу кадәр зурларлар димәгән идем, – дип башлады ул сүзен. – Дәрәҗәле исемгә лаек булырмын дип өмет тә итмәдем, көтмәдем дә. Без бит заманында бер тиен акча алмыйча да эшләгән кешеләр. Акча бирмәгәндә дә, малкайларны кызганып эшкә килә идек. Төрле чаклар булды инде. Фермабыз бетте дигәндә, безне бөлгенлектән коткардылар. Беләсезме кем? Хәзерге район башлыгы. Ул чакта ул үз эшен башлап кына җибәргән кеше иде. Алексей Леонтьев белән бергә фермабызны сатып алып, агрофирма төзеделәр. Хәзер инде Сергей Димитриев хакимияткә күчкәч, бу эшне Алексей Леонтьев алып бара. Эшкә сөенеп барам, сөенеп кайтам. Хезмәт хакы шөкер итәрлек. Инде икенче ел ял йортында сәламәтлегемне ныгытып кайттым. Бушка бит бу!

Рушания апа – Югары Шәмәрдән кызы. Мәктәпне тәмамлый да, 11 ел буе бер партада янәшә утырган дус кызы, адашы Рушания белән фермага юл тоталар. Ул чакта бер төркемдә илле сыер була. Ике сменада эшлиләр. Берсе – иртәнге якта, икенчесе – кич. Сыерларны кул белән савалар.

«Быел гаилә коруыбызга 35 ел була. Их, мин әйтәм, сизелмәде дә бит еллар. Начар яшәгән булсак, истә калыр иде. Үкенечле яшәмәдек», – ди Рушания Ибраһимова.

– Яшьлектер инде. Арымый да идек. Сыерларны савып кайткач, кич клубка чыга идек. Зарланмадык та. 20 яшемдә кияүгә чыктым. Ирем Түбән Шәмәрдән авылыныкы иде. Рушания дә шушы авылга кияүгә чыкты. Аллага шөкер, гомер буе бергә без. Җәйләүләрдә бергә эшләдек. Инде хәзер фермалар заманчалашкач та, икәү бергә аңлашып эшлибез. 50 елдан артык дус без. Ятлар күзе тимәсен. Дустыма бик рәхмәтлемен. Аның белән таулар күчерергә була, – ди Рушания апа.

Ире турында да сораштык. Авылларына телефон номерларын сорап шалтыраткач, Камил абыйныкын биргәннәр иде. Бигрәк ипле сөйләште ул. Әллә безнең белән генә шулай матур аралашамы дисәк, Камил абыйны бөтен тирә-як авыллар хөрмәт итә икән. Җир кешесе ул. Гомере буе басуда эшләп, инде хәзер фермер хуҗалыгын җитәкли. Без шалтыратканда да кырда иде. Рушания апа никтер телефонын алмый дигәч, эшен ташлап, хатыны янына кайтып, безне сөйләштерде.

– Камилем белән бик рәхәт тормышта яшибез. Каенанам да бик әйбәт кеше иде. Кызганыч, әни белән бергә озак яши алмадык. Мин кияүгә килеп, 7 ел узгач, вафат булды. Әмма әнигә мин гомерем буе рәхмәтле. Әле дә сагынып искә алам. Килеп керүгә үз баласы кебек яратып кабул итте. Бер-бер артлы балаларым тугач та, бер авырсынмыйча карады. Авылда декретта дип өйдә утырмыйсың. Ярый әни булды. Өч баламны да сигез ай тулуга калдырып, эшкә чыктым. Шөкер, бер дигән булып үстеләр. Олы кызым үзебез белән, икенчесе Теләче районының Сауш авылында кияүдә. Кияү белән өч бала үстерәләр. Улым белән киленем Казанда яши. Аларның ике баласы бар. Менә кайда ул бәхет! Шушы көннәремне күргәнгә чиксез рәхмәтлемен. Камилемнең ярдәмчел булуы, яратып яшәве аркасында мин бәхетле. Үзем дә яраттым инде, – ди Рушания апа.

Рушания апа, ярый әле фермага төшкәнмен, дигән сүзне еш кабатлады. Шәһәр тормышын яратмый ул. Әле хәзер дә кунакка баргач, бер утырып чәй эчүгә, өйгә кайтасым килә, ди.

– Әгәр киредән яшьлегемә кайтсам, шушы ук юлны сайлар идем. Сыерларым белән шулкадәр рәхәт миңа. Хәзер менә кушаматлар гына бетте. Әмма шулай булса да, кайберләренә Рушания белән исем кушкалыйбыз. Безнең элек бер сыерыбыз бар иде, «Мальва» кушаматлы. Вәт бирә иде ул сөтне! Шуңа охшаган бер номерлы сыер да бар әле. Уйлаштык та аңа да «Мальва» дип йөри башладык. Карарбыз инде, сөте ничек булыр, – ди Рушания апа.

Сөте дигәннән, заманында бер сыерлары 40ар литр сөт биргән. Эш автоматлаштырылгач, кайсы сыерның күпме сөт биргәнен белми башлаганнар. Хәзер сава торганнарының бөтенесе дә сөтле икән. Берсе 60ар литр сөт бирә, ди Рушания апа.

– Фермага яшьләр килми. Инде хәзер кул хезмәте юк. Пычрак ерып йөрмибез. Галош киеп кенә барабыз, – ди ул. – Туган якны, туган җирне яратучылар күп булсын иде. Шәһәрдә сулар һавагыз да юк бит сезнең. Авылларга кайтыгыз! Ә монда эш җитәрлек. Сез түгел, эш сездән куркып торсын!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТЕЛСЕЗ МӨГАЛЛИМ

23 АПРЕЛЬ – БӨТЕНДӨНЬЯ КИТАП ҺӘМ АВТОРЛЫК ХОКУКЫ КӨНЕ

Эшли, укый, социаль челтәрләрдә утыра, тик китап кына укымый. XXI гасыр яшьләре турында еш кына шундый фикер әйтелә. Ә яшьләр үзләре бу хакта ни уйлый. Алардан шул хакта сораштык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Җәмилә СОЛТАНГӘРӘЕВА, модель, 25 яшь:

– Мәктәптән үк әдәбият дәресләрендә китаплар укырга яратмадым. Дөресен әйткәндә, миңа мәгълүматны фильмнар аша кабул итү җиңелрәк бирелә, шуңа күрә әсәрләр буенча төшерелгән фильмнар карыйм.

Психология һәм чынбарлыкка бәйле мәкаләләр укырга яратам. Болар матур әдәбияттагы уйлап чыгарылган вакыйгалар түгел. Әмма хәзер уку өчен вакытым аз, чөнки үземне модель буларак үстерәм: башка шәһәрләргә командировкаларга чыгам, съемкаларда катнашам. Ә буш вакытта йә тренажер залында, йә очрашуларда.

Алмаз ХӨСӘЕНОВ, Туфан Миңнуллин исемендәге Түбән Кама Татар дәүләт драма театры артисты, 29 яшь:

– Теләге булган кеше барыбер китап укырга вакыт таба. Үз тормышымны китаптан башка күз алдына да китерә алмыйм. Китаплардан күңел тынычлыгы алам.

Соңгы укыган китабым – Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр»е һәм «Болганчык еллар»ы. Мондый китапларны укыганнан соң берничә көн шул дулкында йөрисең, уйланасың, нәтиҗә ясап, акыл туплыйсың.

Классик язучыларыбызның, яшь авторларның әсәрләрен дә укырга тырышам. Әйтик, Сәгыйть Рәмиев, Мөдәррис Әгъләм кебек шагыйрьләрнең иҗатын хөрмәт итәм. Ә яшь язучылардан Ленар Шәех, Йолдыз Миңнуллина китапларын кызыксынып укыйм.

Китап уку күңелне баета, фикер тирәнлеген арттыра. Әмма кайберәүләр: «Китап укырга вакыт юк», – дип, сәбәп эзли. Моңа балалар гына гаепле түгелдер, үзебез дә бит китапсыз яшәүне өстен күрәбез. Хәзер кулда – кесә телефоны. Интернет челтәрендә актарынырга барыбызның да вакыты табыла. Китап элек-электән кешенең иң якын дусты дип саналган, ә хәзер интернет китапны акрынлап кысрыклап чыгара башлады. Балаларның китап укымавының мөһим сәбәбе – әти-әнинең китап укымавы!

Китапка мәхәббәт уятыр өчен нәрсә киңәш итәргә була? Беренчедән, кечкенәдән үк, кирәкмәгән уенчыклар алганчы, китап бүләк итегез. Китапларны бергәләшеп уку күпкә кызыграк, соңыннан кечкенә генә спектакльләр куйсагыз, бигрәк тә. Аннан, телефон урынына электрон китапларга кызыксыну уяту файдалырак.

Заманага каршы барып булмый, басма китапка реклама кирәк. Монда ярдәмгә китапханәчеләр килә, алар язучылар, артистлар белән төрле чаралар үткәрергә тиеш. Ягъни укучының язучыга турыдан-туры сораулар бирү мөмкинлеген тудырырга кирәк. Гомумән, бу эш әти-әниләр, укытучылар белән берлектә барырга тиеш.

Адилә ИЛАЛОВА, КФУның 2 нче курс студенты, 19 яшь:

– Рус әдәбиятыннан имтиханга әзерләнгәндә шактый китап укырга туры килде. Исемлектәге ахыргы әсәрләргә җиткәндә, «туры килде» сүзтезмәсе «укыйсы килде»гә алышынды. Шушы әзерлек миндә китапларга карата мәхәббәт уятты. Әлбәттә, көн саен булмаса да, айга бер тапкыр китап тотып карарга кирәк. Хәзерге вакытта психологик китаплар укый башладым. Китап аша үзеңне яратып була икән. Рәхәт бит! Китап ял да иттерә, дөньяны да үзгәртә.

Яшьләргә килгәндә, алар китап укый, минемчә. Хәзер нинди генә жанр юк бит: фанфик (бу популяр әдәби әсәрләр мотивлары, киносәнгать, комикслар, шулай ук компьютер уеннары мотивлары буенча һәвәскәр әсәр), триллер, психологик китаплар. Яшьләрнең кулына көчләп китап тоттырып булмый, шуңа күрә киңәш тә бирә алмыйм. Укыйсы килгән кеше укый.

Илзирә НУРТДИНОВА, Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университетының 3 нче курс студенты, 21 яшь:

– Хәзерге вакытта Кадзуо Исигуроның «Җибәрмә мине» дигән романын укыйм. Шулай ук психология турында әсәрләрне өстен күрәм. Татар әдәбиятын бик сирәк укысам да, Зифа Кадыйрова әсәрләрен киңәш итәм.

Уку бүген ял көннәрен файдалы үткәрү, күзаллауларны киңәйтү, фантазияне үстерү һәм белемнәрне арттыру өчен мөһим. Сүзләрнең ничек язылганын истә калдырасың, кагыйдәләрне белмәсәң дә. Уку шулай ук авырлыкларны хәл итәргә, онытылырга һәм башка чынбарлыкка күз салырга мөмкинлек бирә.

Бу – кызык!

✓ 23 апрельне Халыкара китап көне итеп билгеләп үтү турындагы карар ЮНЕСКО тарафыннан 1995 елда кабул ителә.

✓ Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәгенең 2022 елда үткәргән сораштыру мәгълүматларына карасак, халыкның 92 проценты китап укый. Аларның 58 проценты басма китапларга өстенлек бирә. 61 проценты матур әдәбият яклы. Махсуслашкан (33%), фәнни-популяр китаплар (31%), фәлсәфи әдәбият һәм кулинария китаплары (12%) да популярлар рәтенә кергән.

Илназ ФАЗЛЕТДИНОВ, КФУ укытучысы, 25 яшь:

– Матур әдәбиятны ничек кенә укырга тырышсам да, соңгы вакытта җитешеп булмый. Төп эшем һәм аңа бәйле бурычлар, фәнни-гамәли эшчәнлегем күп вакытымны ала. Бу – укытучы һөнәренең гадәти сыйфаты инде: эшне өйгә дә алып кайту.

Китап уку бәхете дигәннән, Нобель лауреатлары әсәрләренә күз салам. Яраткаларымнан – Герман Гессенең «Степной волк» китабы һәм Михаил Булгаковның «Мастер и Маргарита» романы. Соңгы вакытта төп игътибарым филология, фольклористика һәм журналистика буенча чыккан фәнни хезмәтләргә юнәлгән. Шул исәптән «Фәнни Татарстан» кебек махсус журналларны, Казан университеты чыгарган фәнни мәкаләләр һәм төрле конференцияләр чыгышлары җыентыкларын актив күзәтеп барам.

Үзем дә татар халык авыз иҗаты үрнәкләрен тикшерәм. Максатыбыз – төрки халыклар өчен уртак мәдәни мирас булган «Идегәй» дастанының барлык татар вариантларын табу һәм халыкка тәкъдим итү. Бу эшнең нәтиҗәсе инде күренә. Шул ук вакытта тагын бер юнәлеш – тарихи риваятьләрнең халык язмышын, аның үткәнен һәм бүгенгесен ничек тасвирлаганнарын ачыклау.

Бүген халыкка укымышлы яшьләр түгел, ә төрле блогер, уйлап чыгарылган профессияләр ияләре һәм «эшсезләр» кызыграк. Укымыйча да яшәп була, ләкин эчтән буш икәнсең, халыкка синең файдаң нинди соң? Өлкәннәр шаярып әйтәләр иде: «Баш ул – ашар өчен яки кепка киеп йөртер өчен генә түгел». Әмма моның да тагын бер ягы бар: «укымышсыз»лар күбәйгән саен, алар арасында акыллы булып күренү җиңелрәк, димәк, көндәшлек кими.

Диана КАРПОВА,
КФУның 2 нче курс студенты

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5316 данә
Гомуми тираж – 14278 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 256

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәрриринең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+